ҖӘЯҮЛЕ СӘФӘР
Татарстан Президенты Казан үзәгендәге тарихи объектларның торышы белән танышты
> 2

ТИМУР ЗАҺИТОВ:
«Татар солдатлары хәйлә һәм зирәклек белән алдыра»
> 3

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ:
«Алмазны мин 75 ел беләм»
> 4

КАТАРДА ДА КИРӘК
Әрмән кызы Гаянә Чапанянга татар теле илләр гизгәндә ярдәм итә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 153 (28926) | Сишәмбе | 18 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

АРТЫГЫ ЮК

«ЯРДӘМ ЯНӘШӘ!» ИҖТИМАГЫЙ ХӘРӘКӘТЕ ВОЛОНТЕРЛАРЫ ТАГЫН ЭШКӘ КЕРЕШТЕ

Мобилизацияләнгән егетләргә кирәк-яраклар җыю, аларның гаиләләренә ярдәм итү, бушлай юридик ярдәм күрсәтү... «Ярдәм янәшә!» иҗтимагый хәрәкәте вәкилләре бу көннәрдә әнә шундый зур эш башлап җибәрде. Волонтерлар хәтта караучысыз калган йорт хайваннарын да үз карамагына алмакчы. Ил-көнгә зур сынау килгән чакта ярдәмнең артыгы юк.

Хәтерләсәгез, ике ел элек тормышыбызга «коронавирус» дигән зәхмәт үтеп кергәч тә, «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте волонтерлары иң беренчеләрдән булып ярдәмгә ашыкты. Хәрәкәтнең координаторы Тимур Сафин сүзләренә караганда, пандемия чорында волонтерлар барлыгы 55 мең гаиләгә азык-төлек, кайнар аш тапшырган, 4 меңләп кешегә онлайн рәвештә хокукый, психологик ярдәм күрсәткән, «кайнар элемтә»гә мөрәҗәгать иткән 5 меңнән артык кешегә борчыган сорауларына җавап табарга булышкан.

– Бүген без кабат берләштек. Бу юлы инде мобилизациягә эләккән ир-атларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итәчәкбез. Эшкә керештек инде. Һәр оешма үз юнәлешендә ярдәм күрсәтә башлады. Ярдәм төрләренең саны да арттырылачак. Мондый зур эшне бергә, бердәм булган очракта гына башкарып чыгарга була, – ди Тимур Сафин.

Ярдәм димәктән, бу мәсьәләгә Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та игътибар итте.

– Украинада махсус хәрби операция шартларында безнең батыр хәрбиләр дөньяны, азатлыкны һәм илебезнең киләчәген яклый. Ватанны саклаучыларга ярдәм итү буенча даими рәвештә эш оештырылган. «Ярдәм янәшә!» фонды белән берлектә теләге булган һәр кеше хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтә ала. Моннан тыш, мобилизацияләнгән ир-атларның балигъ булмаган балаларына бер тапкыр 20 мең сум түләү турында карар имзаланды, – диде Рөстәм Миңнеханов.

«Татар-информ»

«Ярдәм янәшә!» хәрәкәте вәкилләре хәзерге вакытта гуманитар ярдәм җыю пунктлары оештырган. Анда мобилизациягә эләккән егетләргә, аларның гаиләләренә ярдәм итәргә теләгән һәркем кирәк-ярак тапшыра ала. Гуманитар ярдәм җыю пунктларының адресы һәм эш графигы белән «ярдәм.рф» сайтында танышырга мөмкин.

«Ярдәм янәшә!» хәрәкәте вәкилләре хәзерге вазгыятьтә төшенкелеккә бирелгән, югалып калган, курыккан кешеләргә психологик ярдәм дә күрсәтәчәк. Тимур Сафин сүзләренә караганда, халыкка юридик ярдәм дә булачак. Бу эш Татарстанның Юстиция министрлыгы белән берлектә башкарыла.

Волонтерлар мобилизациягә эләккән егетләрнең гаиләләренә дә булыша. Әле күптән түгел генә Яшел Үзәндә яшәүче бер анага кышка утын әзерләп биргән алар. Лаеклы ялдагы апаның улы мобилизациягә эләккән. Кышка утын әзерләү мәшәкате дә ялгыз ана җилкәсендә калган. Утынны Яшел Үзән урманчылыгыннан кайтарганнар. Волонтерлар хуҗасыз калган йорт хайваннарын да кайгыртмакчы.

Волонтерлар ярдәменә мохтаҗ кешеләр 8(800) 350-02-16 номеры буенча мөрәҗәгать итә ала. «Ярдәм янәшә!» хәрәкәтенә кушылырга теләгән кешеләргә дә шушы номер буенча шалтыратырга кирәк. Шалтыратулар иртәнге сәгать тугыздан кичке алтыга кадәр кабул ителә.

Әлеге саваплы эшкә үз өлешеңне акчалата да кертергә мөмкин. «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте вәкилләре бу максаттан махсус счет ачты. Акчалата ярдәмне әнә шундый ышанычлы счетларга гына күчерергә кирәк, ди хокук сакчылары. Ник дигәндә, һәр нәрсәдән үзенә файда алырга яраткан мошенниклар бу очракта да тик ятмый. Мобилизациядән коткарырга, йә булмаса, киресенчә, анда эләккән егетләргә ярдәм итәргә вәгъдә итеп, халыкны төп башына утыртулары турында хәбәрләр әледән-әле ишетелеп тора. Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә шул рәвешле Лениногорск районы башлыгын да алдый яздылар.

Гуманитар ярдәм җыю эшендә республика районнары да актив катнаша. Әйтик, Алабуга районыннан мобилизациягә эләккән егетләргә медицина кирәк-яраклары, дарулар, төнге күзәтү җиһазлары җибәргәннәр. Балык Бистәсе егетләренә дә бу көннәрдә районнан кирәк-ярак тутырылган биштәр, дарулар, телефонның зарядкасын тутыру өчен кирәкле пауэрбанк китергәннәр.

Ахыры 2 нче биттә >

Үсмерләргә – фильм

Президент Владимир Путин Россия Хөкүмәтенә балалар һәм үсмерләр өчен фильмнарны тулысынча дәүләт финанславына күчерү турындагы нормаларны закон нигезендә теркәү бурычын куйды. Тиешле йөкләмә Кремль сайтында урнаштырылган. Президент, Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итеп, яшьләрне рухи-әхлакый яктан тәрбияләүгә юнәлтелгән, патриотик рухтагы кинопродукция җитештерү эшен даими рәвештә алып барырга кирәклеген әйтте. Бу эшкә «Интернетны үстерү институты» оешмасы да җәлеп ителәчәк. ТАСС хәбәр итүенчә, киләсе елдан һәм даими рәвештә бу максатларга федераль бюджеттан 3,9 млрд сум бүлеп биреләчәк.

Моннан тыш, Мәдәният министрлыгына быелның 1 декабренә кадәр мәктәп укучыларын даими рәвештә кинотеатрларга йөртүне оештыру буенча тәкъдимнәр исемлеген төзергә кушылган. Владимир Путин әйтүенчә, сүз Россиянең традицион рухи кыйммәтләренә нигезләнгән, балаларны төрле яклап үстерүгә юнәлтелгән фильмнарны күрсәтү турында бара.

Ташламалы ипотека

Россия Хөкүмәте гаилә ипотекасы программасын 2024 елның 1 июленә кадәр озайткан. Бу хакта Министрлар Кабинетының телеграм-каналында хәбәр ителә. Әлеге программа баласы булган гаиләләргә торак алу, шәхси йорт төзү яисә җир кишәрлеге сатып алу өчен, ташламалы ипотека алырга мөмкинлек бирәчәк.

Ташламалы ипотека балалары 2018 елның 1 гыйнвары – 2023 елның 31 декабре аралыгында туган гаиләләргә биреләчәк. Программа буенча ташламалы ставка – 6 процентка кадәр. Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләрендә, Мәскәү һәм Ленинград өлкәләрендә ташламалы ставка буенча субсидияләнүче кредитның максималь күләме 12 млн сумны тәшкил итсә, башка төбәкләрдә ул 6 млн сумга тигез.

2023 елда әлеге программадан 150 меңнән артык гаилә файдалана алачак, ә бирелгән заемнарның гомуми күләме якынча 1 трлн сумга җитәр дип көтелә.

Бурычларсыз тормыш

Югары Ослан районында яшәүче бер ир-ат ярты миллион сумлык кредит алган булган. Суд приставларының әлеге бурыч турында искәртеп торуына карамастан, ир-ат акчаны кире кайтарырга ашыкмаган. Нәтиҗәдә аңа илдән чыгуны чикләгәннәр. Шушы көннәрдә генә бу кешегә чит илгә чыгарга кирәк булган. Һәм ул шунда ук ярты миллион сумлык кредитын тулысынча түләп бетергән.

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча Баш идарәсенең матбугат хезмәте, бурычларны вакытында түләргә кирәк, дип кисәтә. Бурычларыгыз турында мәгълүматны ведомствоның рәсми сайтында яки Дәүләт хезмәтләре порталында табарга мөмкин.

Нульдән түбән төшәчәк

Бу атнада көннәр тагын да суытачак. Бу хакта Татарстанның Гидрометүзәге хәбәр итә. Синоптиклар фаразлавынча, чәршәмбе көнне күпчелек районнарда явым-төшем көтелә. Көндезге сәгатьләрдә һава температурасы +5…+10 градус, төнлә +2…+7 градус булачак. Пәнҗешәмбе, 20 октябрьдә, шулай ук явым-төшем көтелә. Көндез температура +4…+9 градустан да югары күтәрелмәячәк. Төнлә исә 0…+5 градус булачак.

Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, атна азагында Татарстанда явым-төшемнәр көтелми. Көндез температура +1…+6 градусны тәшкил итәчәк. Ә төнге сәгатьләрдә нульдән түбән төшәчәк.

vk.com

Яңалык

Барысы да тигез булсын

Илдәге вазгыять катлаулы булса да, кешеләргә тиешле барлык социаль түләүләр дә түләнәчәк. Пенсияләр дә индексацияләнәчәк.

Дәүләт Думасында федераль бюджет хакындагы закон проектын караячаклар. Төбәкләргә биреләчәк өстәмә акча алдан күз уңында тоткан 5,6 процентка түгел, 8,5 процентка артачак. Сенаторлар бу акчаны да аз дип саный. Өстәмә табыш булган очракта, бу акчаны инфляция дәрәҗәсенә карап, тагын да арттырырга мөмкин икән әле. Бу хакта «Парламентская газета»га Федерация Советының Бюджет һәм финанс базарлары комитеты рәисе урынбасары Елена Перминова хәбәр иткән.

– Дәүләттән бирелә торган барлык социаль түләүләр дә бюджет проектында тулы суммалар белән язылырга тиеш, – ди Елена Перминова. – Киләсе елга да 8 яшьтән 16 яшькәчә балалар үстерүче гаиләләргә түләүләр дәвам итәчәк. Шулай ук 2023 елда ана капиталы акчасында да үзгәрешләр булачак. Ул, инфляция дәрәҗәсенә карап, 12,4 процентка индексацияләнәчәк. Шулай ук киләсе елдан минималь хезмәт хакының күләме артачак.

Россия Финанс министрлыгына яңа төбәкләргә дә ярдәм итү йөкләнде. Сенатор сүзләренчә, ЛНР, ДНР, Херсон, Запорожье өлкәсендә яшәүчеләр дә, Россия төбәкләре кебек үк, үзләренә тиешле социаль түләүләрне алачак. «Безгә яңа кушылган төбәкләрдә яшәүчеләр дә башкалар белән бертигез булсын. Алар да башкалар алган балалар пособиесе, ана капиталы, инвалидлык буенча түләүләр алырга хокуклы», – ди ул.

Федерация Советының Бюджет һәм финанс базарлары комитеты рәисе урынбасары исә, тиздән парламент тыңлауларыннан соң, киләсе өч елга кабул ителәсе бюджетны караганда үз тәкъдимнәрен кертәчәген белдерә.

Россиядә яшәүчеләрнең күбесе ана капиталы акчасының рәхәтен күрде. Исегезгә төшерәбез: 2022 елда беренче балага бирелә торган ана капиталының күләме –

Илдар Мөхәммәтҗанов

524,5 мең сум, гаилә беренче балага бу түләүне алмаган очракта икенчесенә 693,1 мең сум булды. Ә беренче балага бу түләүне алган очракта 168,6 мең сум бирелә. Кайберәүләр шуның ярдәме белән фатирлы булды, торагы булганнар аны зурракка алыштырды. Баласын шул акчаны түләп, бакчага йөртүчеләр, укуына түләүчеләр дә бар.

Казанда яшәүче Ләйсән Хәсиятуллина икенче баласына тиешле ана капиталын әле дә файдаланмаган.

– Ул – безнең өчен бик кадерле акча. Икенче улыбызның үзенә тотарбыз дип торам, – ди ул. – Без дәүләттән үзебезгә тиешле барлык төр түләүләрне алабыз. 8–16 яшьлекләргә бирелә торган «Путин акчасы»н бер ел алдык инде. Гаиләнең кереме аз булгач, социаль түләүләр дә бирелә. Өченче балам инвалид булгач, ташламалардан да файдалана башладык. Илдәге хәлләр тыныч булмаса да, балаларны ничек тә үстерергә кирәк. Ирем, үзе теләп, Украинага махсус операциягә китте. Миңа хәзер әти дә, әни дә буласы. Миңа гына түгел, барлык бала үстерүче әниләр дәүләт ярдәменә ышана. Шуңа күрә бюджетны кабул иткәнче үк, алдан хәстәрен күрсәләр иде.

Сүзгә-сүз

Андрей МАКАРОВ, Дәүләт Думасының Бюджет һәм салымнар комитеты башлыгы:

Бюджет алдында торган бурычлар бүген аеруча әһәмияткә ия. Шуларның беренчесе – дәүләт тарафыннан социаль йөкләмәләрнең үтәлүе. Кешеләр ярдәм чараларының теләсә кайсы вазгыятьтә булачагына ышанырга тиеш. Икенче бурыч – ил икътисадын мөмкин булган барлык үзгәрешләргә яраклаштыру. Дөнья җитди икътисади кризиска якынлаша. Ул Россия икътисадында да чагылыш табачак.

(«Парламентская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ИКМӘК ҖИТЕШТЕРҮ

«Татарстанстат» мәгълүматларына караганда, бу елның гыйнвар – август айларында республикада 86,6 мең тонна күләмендә икмәк-күмәч ризыклары җитештерелгән.





Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ СЪЕЗД ҮТКӘРӘ

Дөньякүләм вакыйгалар киеренке тизлектә агуларын дәвам итә. Планетаның барлык төбәкләрендә дә тормыш шартлары начараюдан риза булмаган халык протест белдерә. Ялларда бәяләр күтәрелүгә риза булмаган французлар демонстрациясе 140 меңгә кадәр кеше җыйды, диләр. Европаның барлык илләрендә дә кешеләр инфляциядән риза түгел. Протест белән хәлне төзәтеп булса икән… Иран фетнәчеләренең гыйсъянчылык хәрәкәте һаман тынмый. Ул инде кан коелуга китерде, байтак кеше корбан булды. Шимбә көнне демонстрантлардан тыш, Ислам революциясен саклаучылар корпусы гаскәриләре дә үтерелде. Үтерелүчеләр арасында полковник Хәмид Реза Хәшеми – гвардиянең разведка корпусы җитәкчесе урынбасары да бар дигән хәбәр алынды. Иран фетнәсе зур тарихи әһәмияткә ия һәм ул дәвамлы булырга охшаган.

Якшәмбе көнне Кытай компартиясе үзенең съездын ачып җибәрде. Съездның тарихи әһәмияте шунда: ул партия лидерының статусын билгеләячәк. Си Цзиньпин җитәкче булып калачагына беркем дә шикләнми. Кытайда ачыктан-ачык оппозиция була алмый, Си сәясәтенә каршы көчләр булса да, алар өстенлекне ала алмады. Съезд алдыннан үткәрелгән пленумда инде барысы да хәл ителде. Әмма бер табышмак кала: Сины партия рәисе дип атарлармы, әллә ҮКның генераль секретаре статусы белән канәгатьләнерләрме? Моның принципиаль әһәмияте бар. Рәис дип аталса, ул гомерлек хакимияткә ия булачак. Генераль секретарь биш ел саен сайлана. Өченче срокка сайларга тиеш түгелләр иде, әмма Си өчен кагыйдәне боздылар, ул хәзер үк өченче тапкыр дилбегәне үз кулында тотып торачак.

Си алып барган эчке сәясәт ковидка каршы аяусыз көрәш, халыкның тормыш дәрәҗәсен туктаусыз күтәрү, 2049 елга – КХРның йөз еллык юбилеена «чәчәк атучы, көчле, демократик, мәдәни яктан үскән заманча социалистик ил төзү» максатын куя. Тик Кытай икътисадының хәле бүген авыр. Дөрестән дә, соңгы елларда чин иле, Японияне узып, дөньядагы икенче икътисад дәрәҗәсенә күтәрелде, эчке тулай продуктның җан башына күләме һәм тормыш дәрәҗәсе ягыннан Россияне артта калдырды. Ләкин күпләп акча басу һәм исәпсез санда кредитлар өләшү нәтиҗәсендә күтәрелгән икътисад тормозга баса башлады: үсеш темплары кими, әҗәтләр бугаздан тота, төзелеш тармагы зур җимерелү алдында. Күз алдына китерегез: илдә торакның гомуми бәясе 52 триллион доллар тәшкил итә, халык байлыгының өчтән ике өлеше ул – торак. Бу куык тишелсә, зур проблемалар туачак.

Чиннарның тышкы сәясәте барыбызга да турыдан-туры кагыла. Әлегә Кытай, аркадаш булмаса да, Россиягә аяк чалмый. Америка – Кытай каршылыгы үсә. Съездда ясаган докладында Си, бер илне атамаса да, АКШның хәрби блоклар төзеп, үз позициясен башкаларга көчләп тагуыннан риза булмавын сиздерде. Иң мөһиме – Тайвань мәсьәләсе. Си утрауны тыныч юл белән Кытайга кушу яклы, әмма барып чыкмаса, хәрби көч куллануга да каршы түгел. Бу планетада икенче зур кораллы каршылыкка китерергә ихтимал. Синың АКШ белән хезмәттәшлекне яклаган оппонентлары булса да, аларның тавышы ишетелә алмый, билгеле.

Россиядә

КӨЧЛӘР ЧАГЫШТЫРМАСЫ ҮЗГӘРЕРМЕ?

Дөнья вакыйгаларының иң киеренке сызыгы Россиянең көнбатыш чикләреннән уза. Барыбызны да борчый бу тема, чөнки киеренкелек кимеми. Көнбатыш дәүләтләренең, Раммаштайнда җыелып, Украинага хәрби ярдәмне арттыру, аңа куәтле һәм заманча һава һөҗүменә каршы тору чараларын тапшыру турында карары хәлне кискенләштерә. Испания дүрт Hawk комплексы бирергә карар итте. Искерәк булса да, илле километр радиустагы объектларны бәреп төшерү куәтенә ия булган андый системалар зур әһәмияткә ия. Французларның кечерәк радиустагы системалар бирү турында вәгъдәсе дә яңгырады. Авыр техника һәм хәтта очкычлар белән тәэмин итү планнары да бар. Дөрес, боларның күбесе вакыт, кайвакыт еллар сорый. Димәк, озак вакытлы конфликтка исәп тоталар.

Шундый шартларда Мәскәүнең аркадашлар эзләве гаҗәп түгел. Үз идеяләрен үткәрү өчен, Кремль шулай ук моңарчы гамәлгә кергән мәйданнарны файдалана. «Азиядә үзара бәйләнеш һәм ышаныч чаралары турында киңәш саммиты» шул мәйданнарның берсе иде. Казахстан инициативасы белән оештырылган мондый очрашу инде алтынчы тапкыр үткәрелә. Быел ул катлаулы шартларда, Токаев сүзләре белән әйтсәк, «тиңе булмаган геосәяси шторм» шартларында уза. Беренче карашка, бу «шторм» Россиянең Украина белән конфликты аркасында килеп чыккан кебек тоелса да, аның асылы башка. Путинның сүзләрен тәрҗемәсез китерик: «Считаем, что требуется запустить пересмотр принципов работы мировой финансовой системы, которая на протяжении десятилетий позволяла самопровозглашенному так называемому золотому миллиарду, замкнувшему на себе все потоки капитала и технологии, в значительной степени жить за чужой счет». Кремль лидеры долларга корылган финанс системасына кизәнә, конфликтны менә шул китереп чыгара. Калган барлык сәбәпләр – сылтау гына. Әйе, ул финанс системасы җимерелеп бара, чөнки бик нык чирли. Вәләкин алтын миллиардка башкалар хисабына яшәргә мөмкинлек бирә торган ул системага Россия гаҗәп дәрәҗәдә бәйле. Мәскәү өчен ул бәйлелектән котылу хәзерге шартларда мөмкин түгел. Хәтта Төркиягә газ илтүче яңа куәтләр булдыру тәкъдимен яңгыратканда да, Путин зәңгәр ягулыкны Көнбатышка сатуны күз алдында тота. Бездән алмасалар, Төркиядән алырлар, дип уйлый.

Саммитта күп идеяләр яңгырады, билгеле, әмма ул – Раммаштайннан аермалы буларак, карарлар кабул итү урыны түгел, киңәш мәйданы гына. Әмма анда лидеры белән катнашкан Кремль стратегиясе (бар илләрнең дә лидерлары килмәде) асылда дөрес. Күбесе мөселман илләре булган Азия дәүләтләре белән яхшы мөнәсәбәт Мәскәү өчен мөһим. Сер итеп кенә әйтәбез: мөселманнар белән яхшы мөнәсәбәттә булганда, НАТО Россия белән туры конфликтка кермәячәк. Путин НАТО белән туры конфликт булуны теләми.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ҮЗЕНЧӘЛЕКНЕ САКЛАРГА

tatarstan.ru

Барлык таләпләргә җавап бирсен. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов башкаланың тарихи үзәгендә төзелүче биналарга шундый таләп куйды.

Иң элек Рөстәм Миңнеханов Казанның тарихи үзәгендә төзелеш объектларын карады. Яңа төзелешнең барлык проектлары да тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия утырышында каралды, аларны кабат карау турында карар кабул ителде.

Ферма-2 урамында комиссия территорияне төзү планы белән танышты. Шәһәрне үстерү институты архитекторлары Рөстәм Миңнехановка тарихи объектлар һәм яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәләрен тәкъдим иттеләр.

Волков урамындагы 12 нче йорт төзелеше белән җитәкчелек инде икенче тапкыр таныша. Беренче тикшерүдән соң бу йорттагы катлар санын киметергә карар кылынган булган. Рөстәм Миңнеханов төзелеш тирәсендәге территорияне дә тәртипкә китерергә кушты. Башкаланың тарихи үзәге – туристларның яраткан урыны. «Шуңа күрә биредәге территория төзекләндерелгән булырга, торак йортларның, шул исәптән агач биналарның тышкы кыяфәте дә билгеле бер стандартларга туры килергә тиеш», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент Һади Атласи урамындагы торак йорт төзелеше белән дә танышты. Биредә 10 фатирлы торак йорт сафка басачак. Бутлеров урамы, 22 нче йорт адресы буенча исә дүрт катлы торак йорт төзелә. Биредә Рөстәм Миңнехановка шушы йортның тышкы ягын эшләгәндә кулланылачак материаллар күрсәтелде.

Ә менә Жуковский урамы, 18а йорты адресы буенча урнашкан аварияле торак йортның хәле катлаулырак. Әлеге йорт салынган җир участогы кадастр исәбендә тормый. Рөстәм Миңнеханов бу мәсьәләне хәл итәргә кушты.

Рөстәм Миңнехановның тарихи үзәккә сәфәре барышында Сара Садыйкова урамындагы ике торак йорт төзелеше дә расланды. Президент аларны төзегәндә яхшы сыйфатлы материаллар гына кулланылырга тиеш дип искәртте.

Алга таба Рөстәм Миңнеханов Каюм Насыйри урамын үстерү проекты белән дә танышты, Мәрҗани мәчетендә булды. Соңгы тапкыр ул 2005 елда төзекләндерелгән булган. Президент реставрация өчен кирәкле документларны әзерләргә, бинаның фасад өлешен, түбәсен тәртипкә китерергә кушты.

Сүз уңаеннан, кичә Рөстәм Миңнеханов башкаладагы яңартылган «Азино» котельныенда булды. «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Рәүзил Хаҗиев сүзләренә караганда, котельныйны яңарту барышында 280 тонна металл конструкция, 105,7 км кабель, 8,5 км торбаүткәргеч монтажланган, 3500 $м^3$ бетон салынган, 28300 $м^2$ территория төзекләндерелгән. Бу җылылык егәрлеген сәгатенә 100 гигакалориягә арттырган. Ул исә, үз чиратында, 140 мең кеше өчен җылытыла торган 3,7 млн квадрат метр мәйданны җылылык белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Кичә Рөстәм Миңнеханов Министрлар Кабинетында «Иннополис» махсус икътисади зонасы Күзәтүчеләр советының чираттагы утырышын уздырды. Махсус икътисади зона составына 4 яңа резидент һәм 6 партнер керде. Компанияләр 153 эш урыны булдырып, 589,1 млн сум акча җәлеп итәчәк.

Мәсәлән, «Русдронопорт» резиденты пилотсыз очкычлар өчен автоматлаштырылган станция төзеячәк. Анда очып китү һәм төшеп утыру, аккумуляторларны һәм ягулыкны саклау, тутыру, техник хезмәт күрсәтү урыннары булачак. «Гемоскан» компаниясе хайваннарның биологик сыеклыклары буенча ясалма интеллект ярдәмендә диагноз кую җиһазларын һәм шуларга программалар җыелмасын булдыру белән шөгыльләнәчәк.

Шулай ук яңа резидентлар арасында «ИЦС Платформа» (төркемле видеоконференцияләр үткәрү, тавыш бирү системасын төзи), Qummy Foodtech (әзер ризыкларны 180 тәүлеккә кадәр саклау технологиясен булдыра), «Газпром ВНИИГАЗ» энергетика компаниясе (Татарстанның фәнни оешмалары белән хезмәттәшлек итү өчен компетенцияләр үзәге оештырырга ниятли) бар.

«ЭнергоИнновации» компаниясе Иннополиста һәм бөтен Россия буенча электромобильләрне кору станцияләре булдыруны максат итеп куя. «БаСтрим» компаниясе, «Андромеда» техспейсы, Test IT, Бизнес фәрештәләре оешмалары берлеге дә махсус зонаның резидентлары булып тора.

«Дөньяда барган вакыйгаларга карамастан, Иннополис, компанияләрне һәм эш урыннарын арттырып, актив рәвештә үсә», – дип билгеләп үтте Премьер-министр урынбасары Роман Шәйхетдинов. Аның әйтүенчә, хәзерге вакытта анда 324 компания эшли, 12,5 мең эш урыны булдырылган, 67 млрд сум инвестицияләр җәлеп ителгән, 122 млрд сум табыш алынган, 17,2 сум күләмендә салым түләнгән.

Икенче җиңү

Казанның «Динамо-Ак Барс» командасы волейболчылары икенче тапкыр Россиянең Суперкубогын яулады. Безнең спортчы кызлар Калининград өлкәсеннән «Локомотив»ны 3:0 исәбе белән җиңүгә ирештеләр. Бүген Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин волейбол клубы җитәкчелегенә юллаган телеграммада команданы зур җиңү белән котлады.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, бу спорт казанышы уенчыларның, бөтен тренерлар штабының, белгечләрнең һәм менеджерларның көндәлек, җентекле һәм киеренке хезмәте нәтиҗәсе булып тора: «Безнең кызлар җанатарларына чын спорт бәйрәме бүләк иттеләр, яхшы уен күрсәттеләр. Әлеге җиңү профессиональ волейболның Татарстанда югары дәрәҗәдә үсешен һәм республика халкы арасында популярлыгын тагын бер кат раслый».

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровка, «Динамо-Ак Барс» клубы президенты, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Леонид Барышевка, клуб директоры Сергей Чернышовка һәм команданың баш тренеры Ришат Гыйлаҗетдиновка бу матур спорт төрен үстерүгә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен рәхмәт белдерде һәм нык сәламәтлек, уңышлар, яңа җиңүләр теләде.

Артыгы юк

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ватан алдында бурычын үтәргә киткән егетләргә ярдәм җыюны үзлегеннән оештырган кешеләр дә шактый арабызда. Чаллыда яшәүче эшмәкәр Рөстәм Гәрәев – шуларның берсе. «Алга» һәм «Тимер» батальоннарындагы якташларына ярдәм итү өчен, «Вместе-к-победе.рф» фондын булдырган ул. Хәзер инде аңа республиканың башка районнарыннан да гуманитар ярдәм җибәрергә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итәләр икән. Бүген берничә эшмәкәр берләшеп, республика күләмендә 25 гуманитар ярдәм җыю пункты булдырган. «Аларның тулы исемлеге фонд сайтына урнаштырылган. Шунда ук җыелган гуманитар ярдәм арасында ниләр бар икәнен дә белергә була. Аларны хәзерге вакытта егетләргә аеруча кирәк булган мөһим әйберләр исемлеге буенча җыябыз. Әйтик, безнең Менделеевск районыннан киткән егетләргә 110 термос кирәк иде. Күптән түгел генә шуларны җыеп җибәрдек», – ди эшмәкәр.

Сүз уңаеннан, «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте алып барган киң колачлы ярдәм эшенә Татарстан Дәүләт Советы депутатлары һәм Аппарат хезмәткәрләре дә үз өлешен кертте. Алар бер көнлек хезмәт хакын мобилизациягә эләккән егетләргә ярдәм фондына күчерде.

«Ярдәм янәшә!» хәрәкәте аша егетләргә акчалата ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен исәп-хисап счеты:
«АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фонды
ОГРН 1061600052425
ИНН/КПП 1658079690/165701001
р/с 40703810100020000999 в ПАО «АК БАРС» БАНК
БИК 049205805
корреспондент счеты 30101810000000000805
«Түләү максаты» дигән графада «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» дип күрсәтергә онытмагыз.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ИГЪТИБАРЫНА

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасы» мәсьәләсе буенча утыз бишенче утырышы С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында (Ирек мәйданы, 3 й.) 2022 елның 20 октябрендә 10 сәгатьтә була.

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышы Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында 2022 елның 20 октябрендә 12 сәгатьтә була.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын теркәү алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышына – С. Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концерт залында (Ирек мәйданы, 3 й.) 2022 елның 20 октябрендә 8 сәгатьтә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы бинасында 2022 елның 20 октябрендә 11 сәгатьтә башланачак.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты

АЛТЫН БӨРТЕКЛӘР

Авыл хуҗалыгы

Теләче районында симәнә заводы эшли башлаячак. Биредә җитештереләчәк орлыкларның 70 проценты «Август-Агро» хуҗалыклары өчен тотылса, калганнарын республиканың башка оешмаларына җибәрәчәкләр. Сәгатенә 10 тонна продукция эшләп чыгарырга тиешле завод Теләче районындагы агрофирма базасында урнашачак.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, әлеге вакытта республикада дүрт симәнә заводы бар. Алар Тукай, Әлки, Лениногорск һәм Буа районнарында урнашкан. Шулай да «Август-Агро» идарәче компаниясенең генераль директоры Айдар Галәветдинов сүзләренчә, сыйфатлы орлыкларга ихтыяҗ зур.

– Без бу эшкә юкка гына алынмадык, – ди ул. – Агросәнәгать комплексында әле барлыкка гына килә башлаган ихтыяҗларның барысын да канәгатьләндереп бетерәсен чамалап, алдан хәстәрен күрдек. Игенчелектә технологияләр үсеш алу белән бергә теге яки бу авыруларга һәм корткычларга бирешми торган сыйфатлы орлыкларга да ихтыяҗ артачак. Соңгы вакытта чит илдән кертелә торган орлыклар белән авырлыклар булуны күз алдында тотсак, безнең проект үз-үзен аклар һәм Татарстанның авыл хуҗалыгы тармагы чәчәк атуга үз өлешебезне кертербез, дип өметләнәбез.

«Август-Теләче» агрофирмасы директоры Алмаз Хәйруллин әйтүенчә, моңа кадәр оешмада ашлык киптерү комплексы төзелгән булган. Биредә сәгатенә 50 тонна ашлыкны чистартып киптерергә мөмкин. Орлык җитештерү заводы исә – әлеге проектның икенче этабы.

– Алга таба безнең алда җитештерү корпусын, һәркайсы 2 мең квадрат метр мәйданлы өч складны, лабораторияләрне эшләп чыгу бурычы тора. Җитештерү линияләре иң заманча җиһазлар белән җиһазландырылачак, – диде Алмаз Хәйруллин.

Симәнә заводында ашлыкны бер кат киптерергә һәм чистартырга да мөмкинлек булачак. Ашлыкны эшкәртү һәм саклау комплексы өчен 600 млн сумнан күбрәк акча тотарга уйлыйлар. Бүгенгә ашлык киптерү комплексы уңышлы гына эшләп килә, ә орлык заводын киләсе елда эшләтеп җибәрмәкчеләр.

– Шуңа күрә киләсе елда көзге культуралар чәчкән чорда заводның зур ярдәмен тоярбыз. Беренче вакытта монда продуктивлыгы югары булган элиталы бодай һәм борчак орлыклары җитештерәчәкбез. Киләчәктә исә башка төрле культуралар белән дә эшләргә планлаштырабыз, – диде җитәкче.

Алмаз Хәйруллин безне әлеге заводның эш тәртибе белән дә таныштырды. Аның   аңлатуынча, алдан чистарту этабында орлыклык материалның яхшыларын сайлап алалар, кабыкларыннан, салам, тузан, минераль һәм органик кушылмалардан чистарталар. Шуннан соң ашлык саклауга куела. Икенче этапта исә калган кушылмалар, чүп үләннәр орлыклары, начар сыйфатлы ашлыклар төшеп кала. Җитәкче сүзләре буенча, чистарту линияләре заманча җиһазландырылачак. Шулай ук киләчәктә Россия базары өчен яңа булган фотосепарация технологиясен дә кулланырга планлаштыралар.

Ашлык, чистартылып, кирәкмәгән вак-төякләрдән арындырылгач, авырулар һәм корткычларга каршы препаратлар белән эшкәртеләчәк. Бу линиядәге җиһазлар орлыкларның өслеген корткычларны агулый торган препаратлар белән берничә кат эшкәртү мөмкинлеге бирә.

– Мондый төр агулаулар бу эшне сак кына башкарырга ярдәм итә. Орлыклар да бер-берсенә ышкылып зарарланмый. Һәм алга таба тагын бер кат киптереп алу да таләп ителми, – дип аңлатты Алмаз Хәйруллин.

Зөһрә САДЫЙКОВА

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«БЮДЖЕТНЫҢ ҺӘР САНЫ АРТЫНДА ЗУР ЭШЛӘР ТОРА»

Бу атнада Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында беренче укылышта республиканың төп финанс документы каралачак. Бюджетта икътисад торышы, халыкның яшәү дәрәҗәсе көзгедәй чагыла. Әлеге документның ничек төзелүе, бүген бюджетның үтәлеше турында сорауларны Татарстан Республикасы финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИНга бирдек.

:: Радик Рәүфович, быел бюджет үтәлеше кәнагатьләндерерлекме? Аны киләсе елга формалаштыруга санкцияләр тәэсир иттеме?

– Елның тугыз аендагы нәтиҗәләре буенча, бюджетыбыз уңышлы үтәлә дип әйтә алабыз. Керемнәр узган елгы күрсәткечләрдән артыграк күләмдә һәм тотрыклы рәвештә туплана.

Җыелучы керемнәр, ел башына калган акча бюджет өлкәсендә эшләүчеләргә хезмәт хакын, бюджет оешмаларының коммуналь хезмәтләре өчен түләргә, башка беренче чираттагы һәм социаль әһәмиятле чыгымнарны, республиканың максатчан программаларын һәм илкүләм проектларны финансларга мөмкинлек бирде. Капиталь төзелеш һәм юл эшләренә акча үз вакытында күчерелә.

Республика икътисадына инвестицияләрне җәлеп итү буенча Татарстан Республикасы Президенты куйган бурычны үтәү максатыннан, салым ташламалары бирелә һәм пландагы чорда да аларны дәвам иттерү күздә тотыла.

Кертелгән санкцияләр шартларында оешмалардагы кыенлыклар республика дәрәҗәсендә дә, федераль дәрәҗәдә дә тиз арада хәл ителә. Мәшгульлекне тәэмин итү, оешмалар, кече һәм уртача эшмәкәрлек өлкәсендә иң күп зыян күргән икътисад тармакларына ярдәм итүнең яңа чаралары эшләнә һәм кабул ителә.

Әйтеп узган шартларда, бюджетның 9 айда һәм ел буенча көтелүче үтәлешеннән чыгып, хуҗалык субъектлары, бюджет акчасын төп бүлүчеләр, муниципаль берәмлекләр белән күпсанлы очрашулар һәм киңәшмәләр нигезендә 2023 елга һәм 2024–2025 еллар план чорына бюджет формалаштырылды.

Финанс документын әзерләү март аенда ук башланды. Бюджет ул – һичшиксез, халыкның тормыш сыйфатын күтәрүдә мәнфәгатьле кешеләрнең бердәм хезмәте.

Сан

2023 елга берләштерелгән бюджет керемнәре – **394,4** млрд сум, чыгымнары – **421,5** млрд сум, кытлык күләме – **27,1** млрд сум. Республика бюджеты керемнәре – **333,9** млрд сум, чыгымнары – **361** млрд сум, кытлык күләме – **27,1** млрд сум.

:: Кытлык күләме шактый. Моңа өстәп, бездә дәүләт бурычы да бар бит. Бу кайбер чыгымнарның үтәлмәвенә китермәсме?

– 2023 елга бюджет дефициты республика бюджетында тупланган. Бюджет кодексы нигезендә, кытлыкны каплар өчен, ел башына калган акчаны, Россия Финанс министрлыгыннан алынган бурычны һәм өстәмә керемнәрне файдаланып була. Федераль бюжеттан кредитлар бирү каралмаган, шуңа күрә без ел башына калган акчага өмет итәбез. Агымдагы елда тупланучы акчаны без 2023 елдагы кайбер чыгымнарга тоту өчен җыеп барырга тиешбез.

Дәүләт бурычына килгәндә, аның күләме законда каралган чикләрдән чыкмый һәм аны кайтару вакыты озайтылды. Быел бу юнәлештә акча каралмаган, бу бюджетны формалаштыруга тискәре йогынты ясар иде.

:: Яңа бюджетта социаль чыгымнарны, шулай ук төрле үсеш программаларын, шул исәптән авыл халкы аеруча үз иткән ихтыярый салым, бакчачыларга ярдәм һәм башка программалар сакландымы?

– Бюджет тормышыбызның барлык өлкәләрен колачлый. Һәм бернинди тармакны да игътибарсыз калдырырга ярамый. Яңа бюджет гадәттәгечә үзенең социаль юнәлешен арттыра, чыгымнарның 80 проценттан күбрәген беренче чираттагы, социаль әһәмияттәге һәм агымдагы чыгымнар тәшкил итә, аларның 50 проценты – хезмәт өчен түләү. Чыгымнарның 88 проценты дәүләт программалары буенча бүленгән.

Сез санап узган программалар саклана гына түгел, аларның күбесе киңәйтелә дә әле. Бер үк вакытта социаль-мәдәни өлкә һәм иҗтимагый инфраструктура объектларын төзү һәм аларга капиталь ремонт ясау дәвам иттереләчәк.

Шулай ук республиканың берничә ел гамәлдә булган социаль әһәмияткә ия чараларын финанслау планлаштырыла, бу юнәлешкә 7,3 млрд сум акча каралган. Алар арасында – яшьләргә патриотик тәрбия бирү, авыл яшьләре, балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру, наркотик куллануны булдырмау, хокук бозуга, террорчылыкка каршы көрәш, талантлар белән стратегик идарә итү һәм башкалар. Бу исемлекне бик озак дәвам иттерергә була.

Барыбызга да мәгълүм хәлләргә бәйле рәвештә, агымдагы ел бюджеты үтәлешенә җитди игътибар таләп ителә. Керемнәр һәм чыгымнар буенча бюджет сыйфатлы үтәлсен өчен, көндәлек җентекле эш алып бару зарур.

Әңгәмәдәш – Диләрә СӘГЪДӘТШИНА

Батырлар

«БАТЫРЛЫК ОРДЕНЫ» ИЯСЕ ТИМУР ЗАҺИТОВ:

«ТАТАР СОЛДАТЛАРЫ ЗИРӘКЛЕК БЕЛӘН АЛДЫРА»

Ватанны сакларга сүз биргән офицер ничек читтә калсын инде? Зәйдә туып-үскән, Кырым, Сүрия һәм менә хәзер Украинадагы хәрби операцияләрдә катнашучы Тимур Заһитов әнә шулай ди. Хәрби һөнәр сайлау – кан тартуымы? Илне ташлап киткән ир затларына карашы нинди аның? Татар солдатлары кайсы сыйфатлары белән аерылып тора? Без батыр егет белән әнә шулар турында сөйләштек.

Тимур Заһитов – иҗади гаиләдә тәрбияләнгән, Зәйдәге татар гимназиясен тәмамлаган егет. 2009 елга кадәр, армиядә хезмәт итеп кайтканчы, хәрби булу турында уйлап та карамаган ул.

– Ләкин хәрби хезмәтемне контракт нигезендә дәвам иттерергә карар кылдым. Тик ниндидер ашыгыч, кисәк кенә кабул ителгән карар булмады ул. Ватанны саклау – уен эш түгел бит, – ди әңгәмәдәшебез. – Патриотик тәрбия, ватанпәрвәрлек рухы белән сугарылган фильмнар тәэсир итте. «Шундый һөнәр бар: Ватанны саклау» дигән гыйбарә аеруча йогынты ясады. Һәм бүгенгәчә шушы юлны сайлавыма үкенгәнем юк.

Егетнең әти-әнисе улларының теләгенә каршы килмәгән. Бүген дә рухын күтәреп, ярдәм итеп торалар икән.

– Билгеле, курка, борчыла инде алар. Тормышыма куркыныч янаганын аңлыйлар бит. Шул ук вакытта минем фикеремне дә беләләр, кабул итәләр. Үз көчеңә ышансаң, бар да яхшы булыр, диләр. Үземнең дә гаиләм бар бит. Хатынга да күнәргә туры килде. Күнми кая барсын инде ул *(көлә)*? Барысы белән дә аралашып торырга тырышам. Хәрби операция дигәч тә, XXI гасырда яшибез бит, якыннарыңа хәбәр салырга мөмкинлекләр җитәрлек, – дип сөйләде Тимур Заһитов.

Батырның батыр туганы

Совет сугышчыларыннан беренчеләрдән булып Рейхстаг бинасы өстенә Кызыл Байрак элгән Гази Заһитов турында ишетмәгән татар юктыр ул. Зәй батыры Тимур исә – аның бертуганының оныгы.

– Бабаларымның батырлыгы һәрчак исемдә. Гази бабам турында кечкенә чакта әти-әни сөйләгәннәрдән ишетеп кенә белә идем. Мәктәптә укыганда, аның исемен тарих китабында күрдем. Шундук горурлык хисе биләп алды. Шуннан соң тәрҗемәи хәле, сугыштагы батырлыклары турында кызыксына башладым. Минем хәрби уңышларымда нәселебездә шундый батырлар булуның да өлеше бардыр, – ди ул үзе.

Бу елның 24 февраленнән бирле Тимур Заһитов Украинадагы хәрби операциядә катнаша. Аның өчен беренче генә операция түгел бу. 2014 елда – Кырымны кайтару буенча хәрби операциядә, ә 2019 елда Сүриядәге хәрби операциядә катнаша. Бүген ул гвардия десант-штурм бригадасында капитан званиесендә хезмәт итә. Күптән түгел генә иң югарылардан саналучы дәүләт бүләге – «Батырлык ордены»на лаек булды.

– Украинага бармый калырга да мөмкинлек бар иде. Ләкин мин бу вариант турында уйлап та карамадым. Мин бит – үз кулларым белән хәрби контракт төзегән, Ватанны сакларга ант биргән кеше. Ничек инде мин илемә кирәк чакта читтә кала алыйм? Тыныч чакта офицер булып йөреп, илне сакларга кирәк булганда артка чигенү – егет эше түгел. Илдән качкан егетләрне дә аңламыйм. Аңламыйм гына түгел, алар турында бик тискәре фикердә мин. Дөньялар тыныч чакта монда рәхәт тормыш күрәсең, үзең яшәгән илеңне «Ватаным» дип атыйсың. Ә шул Ватаныңа кирәк чакта беренче булып чабасың. Юк, чын ир-атлар болай эшләми инде, – ди «Батырлык ордены» иясе.

«Зәй офыклары» сайтыннан

Тимур Заһитов – үзе укыган мәктәптә кадерле кунак.

Хәйләкәр татар солдатлары

Тимур Заһитовтан якташлары – татар солдатлары турында да сораштык.

– Татар солдатлары, Татарстаннан килгән егетләр күп анда. Аларны күргәч, сөенеп куясың. Хәрбиләр арасында бердәмлек бик мөһим бит. Милләтләре, туган һәм торган җирләре уртак булган егетләр, кагыйдә буларак, нәкъ менә бердәмлекләре белән аерылып тора. Аннан соң, татар халкын хәйләкәр һәм зирәк, диләр бит. Татар солдатлары әнә шул сыйфатлары белән алдыра, – ди ул.

Шушы көннәрдә Тимур Заһитов туган ягы Зәйгә кайтты. Үзе укыган мәктәпкә барып, укучылар, укытучылар белән очрашты.

– Туган якка кайтуны һәрвакыт көтеп алам. Кайтканда, күңелне биләп алган хисләрне әйтеп кенә аңлата торган түгел инде. «Кайда тусаң – шунда ярдәмең тияр» дигән гыйбарәнең гаять актуаль чагы хәзер. Башкалар да онытмасын иде шуны, – ди Зәй батыры.

Мобилизациягә эләккән егетләргә һәм аларның якыннарына да әйтер сүзе бар аның.

– Егетләр, хәрби уставта язылганнардан чыкмагыз. Алар – кан белән язылган таләпләр. Устав таләпләрен, куркынычсызлык таләпләрен үтәсәгез, бар да яхшы булачак. Ә инде әти-әниләргә бары яхшыга гына юрарга, бар да яхшы буласына ышанырга киңәш итәр идем. Адәм баласы иманы белән көчле. Алла боерган булса, бар да яхшы булачак, – ди Тимур Заһитов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыяте шартнамәләр үтәлешен контрольдә тоту идарәсенең сәнәгать предприятиеләре белән эшләү бүлеге баш белгече **Андреев** Сергей Владимирович; хезмәт ветераны **Бекмухамедов** Камиль Корбангали улы; хезмәт ветераны **Латыйпов** Рәшит Минһаҗ улы; «Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең агрохимия һәм туфракны өйрәнү кафедрасы мөдире **Миникаев** Рогать Вагыйз улы; «Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе генераль директоры **Хәйруллин** Рөстәм Наил улы; «Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыяте мәгълүмат технологияләре, телекоммуникация һәм элемтә идарәсе башлыгы **Чупаев** Сергей Николаевич; Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы ветераннары (пенсионерлары) советы иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы, җаваплы секретаре **Юнусов** Валерий Исрафил улы; җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция подполковнигы **Симонов** Сергей Сергеевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Ленин исемендәге токымлы терлек заводы авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Гыйлаҗев** Илдус Мансур улына; «Биектау район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Вәлиев** Илдус Ришад улына; Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм транспортта чик буе ветеринария контроле бүлеге башлыгы **Мөхәммәтшин** Илшат Ришат улына; «Курсабаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Саба районы) **Фәсхетдинова** Светлана Андреевнага; Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм транспортта чик буе ветеринария контроле бүлеге дәүләт инспекторы **Шабиев** Логман Фирудин улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирергә.

* * *

«Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Низамова** Фәнисә Мәсгут кызына; «САРМАН» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең баш зоотехнигы (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Шакиров** Рамил Фәһим улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Хезмәт ветераны **Сабиров** Закир Фатыйх улына **«Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Сөләйманов Әхтәм Исмәгыйль улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы тракторчысы (Татарстан Республикасының Нурлат районы) **Богданов** Виталий Петровичка; «Ак Барс» агрокомплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Арча районы) **Габидуллин** Яхъя Зәкәрия улына; «Миңнуллин Генадий Сәмигулла улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы механизаторы (Татарстан Республикасының Баулы районы) **Можгин** Геннадий Евгеньевичка; «Тукай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Шаһидуллин** Фәрит Әнәс улына; «Олы Кариле» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Кама Тамагы районы) **Яруллин** Рәхимҗан Галимҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Азбука сыра» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Мамадыш заводы» филиалы формовщигы **Җиһаншина** Гөлфия Раиф кызына; «Татспиртпром» акционерлык җәмгыятенең «Мамадыш спирт заводы» филиалы сынау производство лабораториясе башлыгы (Мамадыш шәһәре) **Семенова** Нина Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Җырчы шофёр

Арча районының Носы авылы егете, бер ел элек армиядән кайткач, Казанга килә дә маршрут автобусына кондуктор булып эшкә урнаша. Хәзер инде автобус йөртә башлаган. Йөртә генәме әле! Ул көн саен үзенең пассажирларына яхшы кәеф өләшә.

– Бераз эшләгәч, башыма, нигә әле автобус йөртмәскә, дигән уй килде дә, укырга кердем. Йөртү таныклыгы алгач, башта 77 нче маршрутка эшкә куйдылар, аннан 22 нче автобусны йөртә башладым, – дип сөйли Ранил. – Мин биш көн эшлим, ике көн ял итәм. Үземә шулай уңайлы. Эшем кайчак иртәнге биштә башланып төнге уникедә дә бетә. Төрлечә була инде. Иртәрәк кайткан көннәр дә бар. Беренче тапкыр Казан эчендә йөри башлаган көнем әле дә исемдә. Җиңел булмады ул. Каушатты да, куркытты да. Син бит башкалар өчен дә җавап бирәсең. Йөри торгач, ияләндем инде. Эшем үземә бик ошый.

Ранил татар җырларын бик ярата. Радиодан берәр матур җыр ишетсә, шуны эзләп табып, флешкага күчерәм, ди. Салават, Зинира – Ризат Рамазановлар, Рифат Зарипов җырлары аеруча күңеленә якын икән.

– Сез минем җырлаганны каян белдегез әле? Әйе шул, кайчак җырлаштыргалыйм. Элек мәктәп, клуб сәхнәләреннән төшми идем инде. Матур җырлыйсың, дип тә әйтәләр иде. Җырлавым үзем өчен генә минем. Автобустагы кешеләргә дә ошагач, рәхәт инде миңа. Аларның җылы сүзләре йөрәккә май булып ята, – ди Ранил.

Халыкның кәефе ничек? Ранилдән әнә шул хакта да сораштык. Элек кондуктор булып эшләгәндә, төрле кеше белән очрашкан булды, ди ул. Бервакыт салонда буш урыннар бар килеш, тәрәзә янындагы урындык өчен ике хатынның сугышуы хәйран калдырган аны. Шәһәр кешесе бөтенләй башка инде, ди ул.

– Минем әтием дә автобус йөртә. Арчадан авылларга йөри. Әмма бездә кеше бөтенләй икенче. Авыл кешесенең сөйләшүе дә, киенүе дә,

үз-үзен тотышы да башка бит инде аның. Шәһәрнекеләр усал. Ачулы. Кайчак мин ул кешеләрне кызганып та куям. Елмаерга да оныталар бит, – ди Ранил.

Егеткә – 22 яшь. Йөргән кызы да юк әле. Кызлар белән йөрергә вакытым калмый, дип шаярта. Атнаның биш көне эштә уза, калган көннәрендә авылга кайта икән. Анда да кызлар эзләп йөреп булмый, ди.

– Авылыбыз кечкенә генә безнең. Өлкәннәр генә калды инде. Әмма авыл – йөрәктә ул. Исән-сау эшләп, лаеклы ялга чыксам, мин, ике дә уйламыйча, үз нигеземә кайтачакмын, – ди Ранил.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Тәпи басу

Кеше кызык инде кайчагында. И белдекле булып кыланабыз без, и әллә кем кебек сөйләнәбез. Дөньяның асылына бездән дә тирәнрәк төшкән, бездән дә күбрәкне күргән кеше юк диярсең. Мин дә – кеше, мин дә кызык. Кайвакыт бик әллә кем булып интервьюлар биреп кайтам да улымның бәләкәй чагын искә төшерәм. Тәпи басарга маташкан чагын.

Тәпи басарга маташкан баланы күз алдына китерәсез бит инде сез. Дүрт аяклап йөргән җиреннән көч-хәл белән торып баса. Һаваның кайсы төшенә тотынырга белмичә, беркадәр чайкалып тора. Тигезлекне таба, югалта, чайкалып куя, тагын тигезләнә. Елмаеп куя. Кеше өчен түгел, үзе өчен елмая. Атларга дип аягын күтәрә дә шап итеп барып төшә. Еламый. Еламый гына түгел, чыраен да сытмый. Тагын шулай дүрт аяклап, көчәнә-көчәнә торып баса. Тагын чайкалып тора. Атларга итә. Тагын – шап. Һәм меңнәрчә тапкыр шулай.

Кайчагында ул ялгызы гына була. Кайвакыт әллә күпме кешенең карашы астында. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: ул беркемгә дә игътибар итми. Көлсәләр дә, ирештерсәләр дә, аның өчен барыбер. Ул үзен бәяләгәнне ишетергә дә, күрергә дә теләми, ул тәпи китәргә тели.

Ул һәр омтылышын яңачалатып карый. «Болай килеп чыкмады, әһә, менә болайрак итсәң… Әх, алай да булмады, хәзер тегеләйрәк итәбез… Болай да булмады…» – дигән кебек. Ниндидер ачыш өстендә тәҗрибәләр үткәргән фән эшлеклесе диярсең. Профессор, яп-яланаяк!..

Уңышсызлыклар аны борчымый. Газапланмый ул үзенең абынулары, егылулары турында уйлап. Егыла, тора. Тора, егыла. Еламый да, кызармый да, уйлап та бирми.

Ул үзенең һәр яңа уңышы өчен сөенә белә. Елмая. Елмаймаса да, ничектер бар булмышы белән балкып, дәртләнеп китә. Һоп – бу урында егылырга мөмкин иде, ә ул егылмады. Шәп бит! Ул сөенә. Әһә, менә бит, адымга охшашрак хәрәкәт килеп чыкты. Шатлана. Шатланып кына торганда шапылдап барып төшә дә тагын торып, теге шатлыкны эзләргә тотына.

Ул беркемне дә кабатларга омтылмый. Әтисе кебек аякларын да кәкрәйтми, әнисе кебек очаларын да боргаламый, әбисе кебек бөкрәйми дә. Күрше абзый кебек корсагын да киерми. Ул үз адымын эзли.

Һәм таба. Атлап китә. Атлап киткәч тә шатлана гына. Очынмый. Сикергәләми. Белә ул үзенең әле сикерерлек дәрәҗәдә түгелен. Барасы җиренә бара, менәсе җиренә менә, төшәсе җиреннән төшә. Мактанмый. «Фәлән Фәләневич вәт, маладис, дип аркамнан сөйде» дигән яшерен шапырыну ысулын да кулланмый. Тәҗрибә уртаклашкан булып, үз башыннан кичкән маҗараларны күпертеп сөйләми. Башкаларны ничек атларга өйрәтми.

Кечкенә чагында шундый булса да, олыгая төшкәч, кеше кызыкка әйләнә. Ул үзенең һәр адымын, һәр хәрәкәтен башкаларга күрсәтергә, аның өчен яхшы фикер ишетергә тели. Күрмәсәләр, эче поша, хурласалар, үпкәли. Абынуын, яки егылуын күрсәләр, гарьләнә. Ул үзенең уңышлары өчен сөенә белми, чөнки нәфесе һәрчак уңышларыннан зуррак була. Шуңа күрә ул, үз сукмагы, үз адымы турында онытып, башкаларны, үзеннән уңышлыракларны кабатларга маташа. Табаны җылырак урынга тисә, мактана, очына, башкаларны өйрәтергә тотына… Кайчагында элегрәк үзенә терәк-таяныч булган юлдашларын да адәмгә санамый башлый. И кызык инде кеше кайчагында…

Тәпи китү вакыты төрлечә бугай инде ул, кем – сигез айдан, кем – яшь ярымнан. Уртача бер яшь дип алсаң да буладыр. Бер ел.

Әгәр без читләр фикеренә бәйсез булсак, абыну-егылуларыбыз өчен көенмәсәк, һәр омтылышны яңартсак һәм уңышлыларына сөенә белсәк, беркемне дә кабатларга тырышмасак, теләсә нинди проблеманы бер ел тирәсендә хәл итә алыр идек.

vk.com

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе

Рима Андреевна САФИУЛЛИНА

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты ветераны Вадим Рәхим улы Сафиуллинның авыр кайгысын уртаклаша.

СИНЕ КЕМ ДИП БЕЛИК?

Түгәрәк

Сентябрьдә Алмаз Хәмзингә 75 яшь тулды. Юбилее уңаеннан зур тамашалар оештырмады ул. Юкса, сәхнә кешесе буларак, теләсә кайсы залны шыплап тутыра алган булыр иде.

«Татар-информ»

Безнең бергә булуыбыз калсын бөтен гомергә!

Беркөнне авылдашы Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевкә: «Алмазны мин инде 40 елдан артык беләм», – дип мактандым. Ә ул: «Ә мин 75 ел буе беләм, иң якын дустым ул минем», – дип әйтеп куйды. Алар ягы җегетләре кешечә генә сөйләшә белми. «Алар ягы» дигәнем Түбән Кама районы Ташлык авылы була инде. Үзем дә «ташлыкча» сөйләшергә яратам. Разил туганга да: «Сез Алмаз белән ана карынында вакытта ук танышкансыз дип ишеткән бар иде», – дидем. Аларның әти-әниләре «планы буенча» якты дөньяга килүләре – үзе үк гаҗәп хәл. Гыйнварда Разил туган да, әтисе Исмәгыйль абый Алмазның әтисенә: «Наил, минем малайга бер иптәш кирәк булачак бит инде, уйлый-планлаштыра тормыйсызмы…» – дигән. Һәм нәкъ 9 айдан соң Алмаз дөньяга аваз салган. Минем: «Бала ана карынында ук шактый нәрсәне аңлый, сизенә», – дип ишеткән бар. Шуңа күрә Разил туганның: «Без Алмаз белән 75 ел таныш», – дигәне дөрестер, ахры, дип тә уйлап куйдым.

Ике дус башта Ташлык, аннан соң Түбән Кама мәктәбендә укыйлар. Әтиләре аларны авылда калдырырга тели. Исмәгыйль абзый – шахталарда эшләп, авылны сагынып кайткан, колхоз рәисе булып эшләгән кеше. Наил абзый исә партоешма секретаре, аннан соң озак еллар авыл советы рәисе булган.

«Әтиләребез, балалар председатель, партком ук булмасалар да, һич югы главный агроном булырлар, бәлки җитәкче дәрәҗәсенә күтәрелерләр әле, дип уйлаганнардыр», – дип елмая Разил. Үзе, әтисе сүзенә колак салмыйча, шигърият юлыннан китә. Ә Алмаз авыл хуҗалыгы институтына керә, әмма елдан артык укыгач, аны ташлый. Үзе әйтмешли, бер ел сукбай булып йөри, әтисе малайга тәмам кул селти. Тик бераз вакыт узгач, улыннан гафу үтенә Наил абзый. Казанга бер килүендә Алмаз аны опера театрына концерт карарга чакыра, концертта үзе дә җырлый. Ниндидер сәбәп белән Ренат Ибраһимов килмәгәч, аның репертуарындагы Рөстәм Яхинның Рамазан Байтимерев сүзләренә язылган «Туган ягым» дигән җырын Алмазга җырларга туры килә. Тавышы көр егетнең, хәтта тембры да Ренат Ибраһимовныкына якын. Хәер, якын булмаса, аны үзе якынайткан булыр иде, чөнки бу вакытта Алмаз инде музыкаль пародияләр белән мавыккан була. Кыскасы, җырны менә дигән итеп башкара ул, халык гөрләтеп кул чаба, концерттан соң Наил абзый: «Молодец, булдырасың, мин сиңа гел комачаулап килгәнмен икән, гафу ит, улым», – ди.

Разилдән: «Алмазны кем дип белик соң?» – дип сорадым. Бармак бөгә-бөгә санап китте бу. «Ул яшь вакыттан ук яхшы спортчы, көрәшче, биюче иде. Мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза, баянда уйный, үзе җырлый башлады. Ул бит – композитор да, талантлы рәссам да әле. Мин һәрвакыт аңа охшарга, аңа тиңләшергә тырыштым», – диде.

– Шигърияттә дәме?

– Бер гаҗәп хәл сөйлимме? Ничәнчедер сыйныфта укыганда, Алмаз шигырь белән сочинение, ягъни инша язды. Андый хәлне берәүнең дә ишеткәне дә, күргәне дә юк. Укытучы да аптырашта. «Бишле» куяр иде, шигырь белән язу бернинди кагыйдәләргә дә сыймый, начар билге куйсаң – иншасы искиткеч әйбәт. Шактый аптыраганнан соң укытучы аңа «дүртле» куйды. Алмаз минем шикелле шагыйрь булырга гына омтылмады, гаҗәп киң колачлы иҗат кешесе ул, андыйлар бездә бүтән юк та бугай.

Кайчак яшьлек дусларның да юллары аерыла, ә Алмаз белән Разил бүген дә гел бергә. Әлбәттә, Алмаз – армиядә, Разил Мәскәүдә әдәбият институтында укыганда бераз аймыл булырга туры килгән. Әмма гомер юллары барыбер кушылган. Бер уйлаганда, алар – икесе ике кеше. Яшәү рәвешләре, иҗатлары да аерылып тора. Разил шигъриятнең иң югары үрләрен яулады, хакимият арбасына җигелеп тартып, күренекле җәмәгать эшлеклесенә әйләнде. Ә Алмаз дусны мин әдәбият, сәнгать дөньясына мәңгелек сәфәргә чыккан күпкырлы талант иясе итеп күрәм. Ул даимилекне, бер урында гына эшләүне, бер генә нәрсә белән шөгыльләнүне яратмый. Иҗади җаны гел бәргәләнә Алмазның. Озак еллар буе Рифкать Гомәрев җитәкләгән «Саз» вокаль ансамбленең алыштыргысыз солисты булды ул. Татар дәүләт филармониясе җырчысы да иде. Үзенең концерт төркемен дә оештырды, филармониянең эстрада бүлеген дә җитәкләде, директор урынбасары да булды, әмма иҗатын ташламады.

Бер елны филармониягә директор итеп талантлы биюче Әсгать Сафинны куйдылар. Директор бит инде һәр нәрсәгә күз-колак булырга тиеш. Ул чакта пенсиягә чыккан Илһам ага Шакиров филармониянең сәнгать җитәкчесе иде. Иҗат кешесенә иркенлек кирәк бит инде. Илһам ага да вакытында сәгате-минуты белән эшкә килергә өйрәнмәгән. Ә директор һәр иртәдә хезмәткәрләрне барлый. Алмаз моны белә һәм һәр көнне иртүк коридорга чыга да Илһам ага тавышы белән аның репертуарыннан бер җыр башкара. Директор исә гадәтенчә һәр көнне: «Илһам абый эштәме?» – дип сорый торган була. Аңа: «Килгән булырга тиеш, тавышы ишетелә иде», – дип җавап бирәләр. Алмаз Хәмзин ул елларда татар эстрадасында пародия жанрында иҗат итүче бердәнбер артист булмады микән әле дип шикләнәм. Һәрхәлдә, шәхсән үзем башка берәүне дә хәтерләмим.

Заманында Алмаз «Биш татар» исемле миниатюралар театры оештырып, илҗирне айкап йөргән иде. Халык Алмазның тормышы да җай гына, уен-көлке белән генә бара дип уйлыйдыр, бәлки. Ә Разил Вәлиев: «Юмористларның тормышы, гадәттә, шактый ук авыр, хәтта фаҗигале була. Алмазга да шактый кыенлыклар күрергә туры килде. Әмма ул бөтен күңелсезлекләрне дә уен-көлке белән уздырып җибәрергә, халыкның кайгы-хәсрәтен дә таратырга тырышып яши. Бу – бик мактаулы, әмма һәркемнең кулыннан килми торган миссия», – диде.

Алмаз – бик ышанычлы дус. Аңа тулысынча таянырга була. Бу дөньяда үзенә артык берни дә сорамас, югары дәрәҗәләр белән кызыксынмас. Кызыксынса да, «дәрәҗә бирүчеләр»нең бер алдына, бер артына төшеп йөрмәс, ул моны түбәнчелек, мескенлек дип саный. Ә менә дуслары дигәндә…

Янә Разил туган сөйләгәннәрне язып әле. «Мин 30 ел депутат булып тордым. Алты тапкыр сайлауларда катнашырга туры килде. Сайлау алдыннан гадәттә халык белән очрашулар уздырасың бит инде. Минем өчен андый очрашуларны Алмаз оештыра иде. Төрле урыннарда – клубларда, мәдәният йортларында чыгыш ясыйбыз. Мин сөйлим, Алмаз сөйли. Мин шигырьләр укыйм, Алмаз укый. Баянын алып үзенең җырларын да сузып җибәрә. Юморескалар сөйләп, халыкның эчен катыра. Тамашачы безне алкышларга күмә, аннан соң еш кына: «Тукта әле, сезнең кайсыгыз депутат булмакчы соң, кемгә тавыш бирергә?» – дип әйтәләр иде. Менә шул, Алмаз – мине озын гомерле депутат иткән кеше дә», – дигән иде ул. Әле Алмаз турында күләмле әдәби әсәр язарга да нияте бар икән. «Ул безнең яшьлек турында булыр, мөгаен», – диде. Ниятләрең тормышка ашсын инде, Разил туган!

Ә Алмаз дусны юбилее белән котлап нәрсә әйтергә соң? Бервакыт ул миңа әбисе Мәликә турында көлә-көлә сөйләгән иде, озын гомерле, бик шук телле булган әбиебез. 102 яшькә кадәр яшәгән. Моңа 100 яшь тулгач, юбилеена килгән журналистларның берсе: «Мәликә әби, сезнең кебек 100гә җитәр өчен нишләргә кирәк?» – дип сораган. Ә әби ике дә уйламыйча: «Үлмәскә кирәк», – дигән.

Алмаз дус та озын гомерле булсын иде. 100 яшьлек юбилеена килгәч, аннан да озак яшәү серләрен сорашсыннар иде. Һәм Алмаз да «үлмәскә кирәк» дип җавап бирсен иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Без бергә

ГАЯНӘ ЧАПАНЯН:

«ТАТАР ТЕЛЕ КАТАРДА ДА КИРӘК»

Дөнья гизүче әрмән кызы Гаянә Чапанянга татар теле башка халыклар белән аралашу чарасы булып тора. «25 елдан соң әтинең: «Кызым, татарча өйрән», – дигән сүзләре миңа Катарда башка халыкларга эш барышын татарча аңлатырга ярдәм итәр дип кем уйлаган?» – дип гаҗәпләнә ул. Бүген ул – Катарда футбол стадионын дөнья чемпионатына әзерләүчеләрнең берсе. Аны нәрсәләр шаккатырган?

Катарда 21 ноябрьдә футбол буенча дөнья чемпионаты башлана. Хәзерге вакытта Гаянә – Лусаил һәм 974 нче стадионны җиһазлау буенча менеджер. Монда ул ике айга килгән. Аның Татарстанның төрле шәһәр һәм районнарында эшләгәне бар, республикада ачылган «Адымнар» мәктәпләрен, Әлмәттәге «Орленок» лагерен җиһазлауда катнашкан. Чит илдә исә бу – аның беренче тәҗрибәсе. Бер ел элек, эш өчен кирәк дип, инглиз телен дә өйрәнә башлаган. Җиһазлау эше бик ошый, логистика буенча яки башка авырлыклар туса, без аны команда белән башкарып чыгабыз, ди.

– FIFA World Cup чемпионатын оештыручылар 2018 елда Россиядә узган чемпионаттан бик канәгать калган. Шуңа күрә аннан бик күп белгечләрне җәлеп иттеләр. Россия – минем өчен иң яхшы ил. Әлбәттә, Катарда стадионнар зуррак. Футбол өчен күп акча түгәләр. Тик чемпионат узгач, стадионнарны мәктәп, укыту оешмаларына бирәләр яки башка максатларда файдаланалар. Әйтик, Лусаил стадионына 80 мең җанатар сыя. Чара узгач, монда аз керемле илләргә футболны үстерергә ярдәм итәргә җыеналар. Урындыкларын, җиһазларын да башкаларга бирәчәкләр. Стадионның бер өлешен генә үзләренә калдырачаклар, – ди Гаянә.



Гаянә Грузиядә туган. 1996 елда гаиләләре белән Татарстанга күченеп килгәннәр. Дөресрәге, СССР таркалгач, клуб мөдире булган әтисе эшсез калган. Шуннан соң Татарстанга төзелешкә килергә мәҗбүр булган. Аннан инде гаиләсен дә үзе белән иярткән.

– Татарстанга килгәч, әти миңа таләп куйды. «Кызым, син татарлар арасында яшисең, шуңа күрә аларның телен, гореф-гадәтләрен мәҗбүри өйрәнергә тиеш. Бу – шунда яшәүче урынга һәм биредәге халыкка хөрмәт билгесе. Син аларны аңлаганда, үзеңә дә зур файда булыр», – диде. Мин татарча азмы-күпме 6 яшьтә сөйләшә башладым. Без күченеп килгән беренче авыл – Питрәч районының Ковал авылы иде. Балалар белән уйнау өчен миңа татарча белергә кирәк иде. Тәүге татар сүзләрен мәйданчыкта ишеттем. 1 нче сыйныфтан исә татар телен бик тырышып өйрәнә башладым. 6–11 сыйныфларда Биектау районының Алан-Бәксәр мәктәбендә укыдым. Татар теленә мәхәббәтне миндә укытучым Айсылу Мөбарәкҗан кызы уятты. Татар теленнән район буенча узган олимпиадада рус телле балалар арасында өченче урын яулаган идем, – дип сөйләде Гаянә. – Без яшәгән ике авылда да безгә, читтән килүчеләр, дип кырын карамадылар. Татарлар белән туганлашып беттек. Кавказ халкының йола, гореф-гадәтләрен дә сакларга тырышабыз. Шул ук вакытта татар теле мәдәниятен дә яратам. Татарча биим, җырлыйм. Әнвәр Нургалиев, Гүзәл Уразованы бик яратып тыңлыйм. Бик күп концертларда булдым.

Алан-Бәксәрдә әтисенең кибете бар икән, менә шунда Гаянә бер ел сатучы булып эшләгән. Авыл апалары, әбиләре белән рәхәтләнеп татарча аралашкан. Кызны гел мактап торганнар. Казандагы сәүдә һәм икътисад университетын тәмамлаган кыз бүген инде яңа биеклекләр яулый.

– Мин татар теленең үзбәк теле белән охшаш булуына шаккаттым. Хәзерге вакытта безнең командада Үзбәкстаннан вәкилләр күп. Кайберләре русча белми, аларга нәрсә эшләргә кирәклеген татарча аңлатам, барысын да җиренә җиткереп башкаралар. Бүген әле менә сезнең белән татарча сөйләшкәнне ишетеп, кул чаптылар, – дип шатланып куйды Гаянә.

Чит илләрдә матур, рәхәт булса да, үзеңнең торган җиргә бернәрсә дә җитми. «Кая гына булсам да, Татарстан кебек күңелгә рәхәт урын таба алмыйм. Тизрәк Казанга кайтуны көтәм. Әнинең өчпочмакларын сагындым. Алан-Бәксәрнең әремнәренә кадәр якын миңа», – ди Гаянә Чапанян.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6715 данә
Гомуми тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 353

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+